# Әдәп төбе - матур гадәт

Кеше булып калу өчен Әдәплелек - иң төп сыйфат. Тәмле телле булу, шәфкатьлелек һәр кеш

Минсафина А.Г.









“Марат мәктәп коридорында бер төркем укытучыларның сөйләшеп торуын күреп, сыйныф җитәкчесе белән генә исәнләшеп узып киткән. Марат дөрес эшләгәнме? Ярдәм итик әле, ул нишләргә тиеш булган?”



“Кешеләр бер-берсе белән исәнләшкәндә, салют, привет, сәлам, чао, исәнмесез, исәнме, әссәламәгәләйкем сүзләрен кулланалар.

Ә сез бу сүзләрне дөрес куллана беләсезме?”



"Танышлар булмасак та,

Бер-беребезгә баш иеп исәнләштек: Исәнмесез!

Бер-беребезгә нинди сүз әйттек?

"Исәнмесез"дән башка бер сүз әйтмәдек.

Ә нидән соң бер тамчы кояш артты дөньяда? Нидән соң бер тамчы шатлык артты дөньяда?"

Сез ничек уйлыйсыз исәнләшкәч, ни өчен шатлык арта икән?



“Классташыгыз бәйрәмгә яңа күлмәк киеп килгән. Сез аны күрүгә...

“Дәвам итегез әле минем сүземне”,-ди төлке.



“Малайлар футбол уйный иде. Руслан бар көченә тупка китереп типте. Тик аның аягы тупка түгел, ә Айратның тезенә тиде. Айратның тезе бик авыртты. Шулай да ул еламады. Бу очракта Руслан ни эшләргә тиеш?”



“Шул сүзләрне бер кат уку белән күңелдән кайсыгыз сөйли ала?

- Тәмле сүзләр:

“Хәлвә”, “шикәр”, “бал”.

Салкын сүзләр:

“Буран”, “давыл”, “кар””.



“Урманның иң матур җирендә-

Зур аланда торам мин.

Малайлар һәм кызлар! Сезне кунакка чакырам мин”



# Мәкальләр

- 1. Җылы сүз...
- 2. Яхшы тел...
- 3. Яхшы сүз...
- 4. Татлы сүз..
- 5. Теле татлының...
- 6. Сөйдергән дә тел,...
- 7. Сүзнең башыннан элек...

# Хикәя

Нияз, автобуска утырып, урамны карап бара. Тукталышта автобуска бала күтәргән ана керә. Нияз тиз генә урыныннан тора һәм болай ди: “........................”.

Әни кеше дә бик әдәпле була . “....................”,- ди малайга.

Автобус кинәт туктый. Нияз, чайкалып китеп, бер өлкән кешенең аягына баса. Ул абзый малайны ачуланырга тели. Нияз аңа: “...............................”, - ди.

# Сөйләм әдәбе кагыйдәләре

## Исеңдә тот:

- кеше белән елмаеп исәнләш;
- кешене сөйләвеннән бүлдермә;
- сөйләшкәндә кулларыңны болгама;
- “мин” сүзен еш кабатлама;
- “гафу итегез” димичә, кеше сүзенә кушылма;
- сөйләшкәндә тылсымлы сүзләр кулан;
- кеше белән сөйләшкәндә, читкә карап торма, аны игътибар белән тыңла;
- сөйләшәп бетермичә яки әңгәмәдәшеңнән рөхсәт сорамыйча урыныңнан торма;
- кешегә бармагың белән төртеп күрсәтмә;
- аерылышканда ягымлы итеп саубуллаш.

# Әдәпле кеше нинди була?

- Кешеләр белән дөрес аралаша белә;
- Кешеләргә игътибарлы, шәфкатьле;
- Үзенең якыннары, дуслары турында кайгыртып яши, аларга ярдәм итәргә әзер тора.


Әдәпле бала
Шәфкатьле
Гадел
Игътибарл
ы
Тәмле телле
Тәуфыйклы
Намуслы
Инсафлы
Кешелекле
Тәрбияле
Мәрхәмәтле
Ярдәмчел